КАБИНЕТ МИНИСТРОВ
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

2025 ел, 20 июнь г.Казань № 449

Алабуга муниципаль районы акваториясендә «KAMA FEST – 2025» гаилә фестивален уздырганда су объектларыннан файдалану турында

Россия Федерациясе Су кодексының 6 һәм 25 статьялары, Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасы территориясендә урнашкан су объектларында кешеләр тормышын саклау кагыйдәләрен раслау турында» 2009 ел, 23 апрель, 256 нчы карары белән расланган Татарстан Республикасы территориясендә урнашкан су объектларында кешеләр тормышын саклау кагыйдәләренең 1.3 пункты нигезендә, Алабуга муниципаль районы акваториясендә «KAMA FEST – 2025» гаилә фестивален уздырганда кешеләр тормышы иминлеген тәэмин итү максатларында Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты КАРАР БИРӘ:

1. Алабуга муниципаль районы акваториясендә «KAMA FEST – 2025» гаилә фестивален уздыру чорында 2025 елның 21 июнендә 6 сәгать 00 минуттан 14 сәгать 00 минутка кадәр, 2025 елның 22 июнендә 4 сәгать 00 минуттан 18 сәгать 00 минутка кадәр Алабуга утравы территориясендәге Кама елгасы участогында яр буеннан 600 метр ераклыкта аз сыешлы суднолардан, шулай ук җилкәнле, ял итү, спорт судноларыннан (гидроцикл, байдарка, ишкәкле көймәләрне кертеп) файдалану тыела (алга таба – тыю) дип билгеләргә.

2. Татарстан Республикасы Гражданнар оборонасы эшләре һәм гадәттән тыш хәлләр министрлыгына халыкка кертелә торган тыю турында, шул исәптән массакүләм мәгълүмат чаралары аша мәгълүмат бирү эшен оештырырга.

3. Россия Федерациясе Гражданнар оборонасы эшләре, гадәттән тыш хәлләр һәм табигый бәла-казалар салган зыяннарны бетерү министрлыгының Татарстан Республикасы буенча баш идарәсенә тыюны үтәү максатларында көчләрнең һәм чараларның кизү торуын тәэмин итүне тәкъдим итәргә.

4. Тыю «КАМА FEST – 2025» гаилә фестивален әзерләү һәм уздыру өчен җәлеп ителгән судноларга кагылмый дип билгеләргә.

Татарстан Республикасы
Премьер-министры А.В.Песошин